КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 сентябрь г.Казань № 1117

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибен (куллану турында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибен) раслау турында» 2016 ел, 1 март, 124 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибенә (куллану турында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибенә), 4 пунктындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 ел, 28 февраль, 178 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин